РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
Алькеевского сельского
поселения
Азнакаевского муниципального
района

Пер.Советский,44а,
423309 Тел. ( 885592) 37-4-23

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Әлкэй авыл жирлеге
советы
БАШЛЫГЫ

Пер.Советский, 44а
Әлкэй авылы, 423309
Тел. (885592) 37-4-23

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

"11" ноябрь 2019 ел №40

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 23.11.2019 ел Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Кызыл сукачы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 23 ноябрь 2019 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Кызыл Сукачы авылы, Чапаев ур., 26 йорт, (Миннебаев.М.М шәхси йорты) ;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Әлкәй авылы, Пер.Совет ур.44а йорт;
- сайлау хокукына ия булган Кызыл Сукачы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Кызыл Сукачы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу

акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кызыл Сукачы авыллары юлларын кардан чистарту;

« РИЗА» «КАРШЫ”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әлкәй авылы,пер.Совет ур.,44а йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: С.З.Зиннурова